**Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы**
**Әлкәй авыл җирлеге Советы**
**КАРАРЫ**

Әлкәй авылы № 65 21.09.2017 ел

Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Әлкәй авыл җирлеге Советының 2016 елның 31 маендагы 33 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Әлкәй авыл җирлегенең муниципаль мөлкәтен хосусыйлаштыру тәртибе турындагы Нигезләмәгә үзгәреш кертү хакында

«Дәүләт һәм муниципаль мөлкәтне хосусыйлаштыру турында» Федераль законның 5 статьясына һәм «Ил оборонасын һәм дәүләт иминлеген тәэмин итү өчен стратегик әһәмияткә ия хуҗалык җәмгыятьләренә чит ил инвестицияләрен гамәлгә ашыру тәртибе турында» Федераль законга үзгәрешләр кертү хакында» 2017 елның 01 июлендәге 155-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә

Әлкәй авыл җирлеге Советы карар кабул итте:

1. Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Әлкәй авыл җирлеге Советының 2016 елның 31 маендагы 33 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Әлкәй авыл җирлегенең муниципаль мөлкәтен хосусыйлаштыру тәртибе турындагы Нигезләмәгә 5 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итеп, түбәндәге үзгәрешне кертергә:

«5. Муниципаль мөлкәтне теләсә кайсы физик һәм юридик зат сатып ала ала, моңа:

дәүләт һәм муниципаль унитар предприятиеләр, дәүләт һәм муниципаль учреждениеләр;

«дәүләт һәм муниципаль мөлкәтне хосусыйлаштыру турында»2001 елның 21 декабрендәге 178-ФЗ номерлы Федераль законның 25 статьясында каралган очраклардан тыш, устав капиталында Россия Федерациясе, Россия Федерациясе субъектлары һәм муниципаль берәмлекләр өлеше 25 проценттан артыграк булган юридик затлар;

салым салуның ташламалы салым режимын бирүче һәм (яисә) финанс операцияләре үткәргәндә (офшор зоналары) мәгълүматны ачуны һәм бирүне күздә тотмаган дәүләтләр һәм территорияләр исемлегенә кертелгән теркәлү урыны дәүләт яисә территория булган юридик затлар (алга таба-офшор компанияләр);

офшор компаниясе яки офшор компаниясе кергән затлар төркеме тарафыннан контроль башкарыла торган юридик затлар.

«Затлар төркеме» һәм «контроль» төшенчәләре «Конкуренцияне яклау турында»2006 елның 26 июлендәге 135-ФЗ номерлы Федераль законның 9 һәм 11 статьяларында күрсәтелгән мәгънәләрдә кулланыла.

Әлеге пунктта билгеләнгән чикләүләр, күрсәтелгән милекчеләр әлеге җир кишәрлекләрен сатып алганда, ирекле төзелешләр булмаган һәм муниципаль

милеккә караган җир кишәрлекләрендә урнашкан күчемсез мөлкәт объектлары милекчеләренә кагылмый.

Конституциячел корылыш нигезләрен, башка затларның әхлагын, сәламәтлеген, хокукларын һәм законлы мәнфәгатьләрен яклау, дәүләтнең оборона сәләтен һәм иминлеген тәэмин итү максатларында физик һәм юридик затларның аерым категорияләренең граждан мөнәсәбәтләрендә катнашуына федераль законнарда билгеләнгән чикләүләр муниципаль мөлкәтне хосусыйлаштырганда мәҗбүри.

Акционер җәмгыятьләр, җаваплылыгы чикләнгән җәмгыятьләр «дәүләт һәм муниципаль мөлкәтне хосусыйлаштыру турында " 21.12.2001 ел, № 178-ФЗ Федераль закон нигезендә хосусыйлаштырыла торган үз акцияләрен, устав капиталларындагы үз өлешләрен сатып алучылар була алмыйлар.».

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында түбәндәге веб-адрес буенча бастырып чыгарырга: http://pravo.tatarstan.ru һәм Азнакай муниципаль районының рәсми сайтында Интернет "мәгълүмат-коммуникацион челтәрендә түбәндәге веб-адрес буенча» урнаштырырга: http://aznakaevo.tatar.ru.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны законлылык, хокук тәртибе, депутат этикасы һәм җирле үзидарә мәсьәләләре буенча даими комиссиягә йөкләргә.

Рәис С.З.Зиннурова